УДК 811.512.145’373.23 +39 (512.145)

# Татар ономастиконында борынгы төрки исемнәр

*Г. С. Хажиева,*

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан шәһ., Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе*

# Old Turkic personal names in the Tatar onomasticon

*G. S. Khaziyeva,*

*G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Kazan, the Republic of Tatarstan, the Russian Federation*

**Аннотация**

В статье анализируются особенности функционирования древнетюркских личных имен в татарском ономастиконе. Материалом исследования выбраны опубликованные тексты орхоно-енисейских памятников. Исследователи данных памятников до сих пор ограничивались лишь изучением палеографических проблем и попутно обращались к осмыслению отдельных антропонимов в орхонских и енисейских надписях. Однако до настоящего времени в тюркологии отсутствуют комплексные монографические исследования личных имен в орхоно-енисейских памятниках, выполненные в диахроническом аспекте. Автором отмечается, что описание развития и становления современных тюркских языков, в том числе их антропонимических систем, – это результат выявления общности и различий именника того или иного тюркского народа, чья антропонимическая система складывалась в течение тысячелетий – в процессе консолидации этноса с родственными и неродственными этносами. В статье показано, что в древнетюркской системе личных имен отразились ступени развития и формирования государственного строя тюркских народов, историческое развитие их языков. Рассмотрены особенности древнетюркского пласта личных имен, который проявляется в единой связи тюркских этнических групп эпохи орхоно-енисейских памятников. Обнаруживаются параллели между татарскими и тюркскими именами в других языках. Установлено, что соответствующие тюркоязычные этносы со времен первых письменных памятников уже достаточное время существовали отдельно друг от друга, что и заложило основы их антропонимической дивергенции. У древних тюрков имена давались при рождении, после рождения: в юности, в молодости, в старости. Имена, полученные при рождении, назывались «ада атым», «оглан атым», полученные после рождения – «эр (ир) атым», их получал любой юноша, достигший определенного возраста. Каждый воин обозначался термином эр (ир), получение которого было связано с обрядом инициации, которому предшествовало совер-

шение юношей охотничьего или воинского подвига. К имени уже получившего мужское имя присоединяются различные титулы, указывающие на его известность или место в военно-административной иерархии каганата. В статье рассматриваются различные названия титулов, присоединяющихся к именам, полученным при рождении. В древнетюркской культуре именования изменение титула человека, повышение по социальной лестнице становилось причиной переименования. Резюмируя, следует сказать, что титулярные названия играли важную роль в образовании личных имен в древнетюркском языке.

**Abstract**
The article analyzes the peculiarities of the functioning of the Old Turkic personal names in the Tatar onomasticon using the example of the published texts of the Orkhon-Yenisei monuments. Up to now the researchers of these monuments have been restricted to the study of paleographic problems and simultaneously conceptualized certain anthroponyms in the Orkhon and Yenisei inscriptions. However, in Turkology still there are no comprehensive monographic studies of personal names in the Orkhon-Yenisei monuments in terms of diachronic aspect. The author notes that the description of the development and formation of modern Turkic languages, including their anthroponymic systems, is the result of revealing their common traces and differences in the mark of a certain Turkic nation, the anthroponymic system of which was formed for thousands of years during the consolidation of an ethnic group with kindred and non-kindred ones. The article shows that the Old Turkic system of personal names reflected the stages of development and formation of the state system of the Turkic peoples and historical development of their languages. The work considers peculiarities of the Old Turkic layer of personal names which is manifested in a single connection of the Turkic ethnic groups belonging to the period of Orkhon-Yenisei monuments. The author finds parallels between Tatar and Turkic names in other languages. It is stated that the related Turkic ethnic groups existed separately from each other since the time of the first written monuments which laid the foundation for their anthroponymic divergence. Old Turks' names were given at birth or after birth – in youth, younger days and in old age. The names received at birth were called "ada atym" and "oglan atym", the ones received after birth – "er (ir) atym" which were given to any young man of a certain age. Each warrior was denoted by the term "er (ir)", the receipt of which was associated with the rite of initiation having been preceded by the accomplishment of a hunting or military feat by a young man. Having received a man's name, various titles were attached to it, indicating his fame or place in the military-administrative hierarchy of the Kaganate. The article describes various title names attached to the names obtained at birth. In the Old Turkic culture of naming the change of a person's title or rising on the social scale became the reason for renaming. In summary, it should be noted that title names played an important role in the formation of personal names in the Old Turkic language.

**Ключевые слова**
Татарские личные имена, антропонимика, древнетюркские имена, орхоно-енисейские памятники.

**Keywords**
Tatar personal names, anthroponymy, Old Turkic names, Orkhon-Yenisei monuments.

Татар теле үзенең үсешендә озын һәм катлаулы юл үткән. Аның үсеше төрки халыкларның үсеше белән тыгыз карала. Төркиләрнең безнең эрага кадәр III-II меңьеллыкта яшәгәнлекләре билгеле. Аларның үзләренә генә хас теле, мәдәнияте, яшәү рәвеше булуы мәгълүм. Төркиләр күккә, кояшка, айга табынып яшәгәннәр. Аларның бердәнбер Алласы – Тәңре булган. Борынгы төркиләр тәңречелек культына буйсынганнар. Борынгы төркиләрнең тирә-юнь чынбарлыгына булган күзаллаулары,

табигый ки аларның антропонимик системаларына тәэсир итми калмый. Борынгы төрки исемнәр катламы формалашканда, һәм телнең тарихи үсеш үзенчәлекләрен төрле субстрат, адстрат элементларның бәйләнешен үз эченә туплап, төрки халыкларының дәүләтчелекләрен барлыкка китергән һәм аларның үсеш этапларын да чагылдырган катлаулы бер системасын булдырган. Борынгы төрки катлам исемнәре төрле дәрәҗәләрдәге, бердәм комплекстагы төрки этник төркемнәрнең (болгар, кыпчак, угыз, карлук, уйгыр-угыз, кыргыз-кыпчак) үзара бәйләнеше белән үзенчәлекле. Татар антропонимикасының төрки катламы төрки телләр үсеше чорларында (Борынгы төрки чорда, ягъни (V-X гасырлар), Урта төрки чорда (X-XV гасырлар), Яңа төрки чорда (XV-XX гасырлар) формалашкан һәм, шул нигездә, халыкның рухи һәм матди мәдәниятен тулы итеп чагылдырган. Төрки халыкларда антропонимнарның беренче үрнәкләре орхон-енисей, уйгыр язмаларында билгеләнә. Безнең эрага кадәр VIII-VI гасырларда Үзәк Азияне, Төньяк Кытай, Монголия, Себер, Казахстан, өлешчә Иран җирләрен үз эченә алган Төрки каганлык – төрки халыкларның дәүләте төзелә. Төрки каганлык чоры – гомумтөрки мәдәниятнең оешып бетеп, үзенә күрә бер борынгы классик үсешкә ирешкән вакыты. Шул чорда тәмам оешып җиткән тәңречелек төрки халыкларда ислам дине кабул ителгәнче гамәлдә була[1]. Татар исемнәренең борынгы төрки катламы тәңречелек концепциясендә кеше һәм табигать стихиясе бәйләнешен характерлый. Кеше һәм табигать бәйләнеше турыдан-туры Күк-тәңре атрибутларыннан саналган кояш, ай, йолдызлар культы атамаларыннан ясалган борынгы төрки ир-ат исемнәрендә чагыла. Мәсәлән, бүгенге көндә дә татарларда, башкортларда[2], төрекләрдә[3], үзбәкләрдә[4], казакъларда[5] ай, күк-гөк, офык, көн, таң кебек антропокомпонентлардан ясалган ир-ат исемнәре борынгы төрки катлам ир-ат исемнәренә карыйлар. Шулай ук космонимия, төрле табигать күренешләре атамалары нигезендә ясалган ир-ат исемнәре борынгы катлам исемнәрен тәшкил итәләр.

Тәңре – төрки халыкларда синкретик күренеш. Ул, фәлсәфи субстанция буларак, һәрнәрсә һәм һәрнәрсәне барлыкка китерүнең сәбәбе булып тора һәм, теистик субстанция буларак, нәсел башы, яхшылык һәм яманлык чыганагы да (Тәңребиргән!). Руник язмаларда чынбарлык Тәңре тарафыннан яратылган дип языла. Тәңре – борынгы төрки дөньяның югары хакимлеккә ия көче. Төркиләр аны Күк-тәңре дип тә атаганнар. Космосның бер өлеше, Тәңре буларак, руник текстларада «kök tenri» дип аталган һәм борынгы төрки чыганакларда төрле формада чагылыш таба, kök (kök qalyq, qalyq «һава»); шуңа күрә аның тагы бер мәгънәсе якын күк йөзе, кошларга якын күк йөзе белән дә бәйләнешле аңлатыла[6]. Борынгы төрки дини күзаллаулар буенча Тәңре – ул, беренче чиратта, Күк тәңресе. Тәңре дөньядагы һәрнәрсә белән, кеше язмышы белән идарә итә. Борынгы кеше галәмне яраткан Күк-тәңрегә буйсына[7]. Билге каганнның кече улының исеме Күк-тәңрегә бәйле – орТәңре каган (734-741 еллар). Борынгы кеше галәм, хаос, җиһанны тудырган күк алласына буйсына, Тәңре кулында яши. Илаһи көчнең атамасы булган Тәңре сүзе[8] татар исемнәрендә (Тәңребиргән, Тәңребирде, Тәңрегол) һәм башкалар да кулланылган һәм казакъ[9], үзбәк[10], кыргыз[11], төрек[12] һәм башка төрки халыкларның уртак хәзинәсен тәшкил иткән. Р. Әхмәтьянов чыңгыз исеменең этимологиясен тәңре атамасына бәйле карый. Аның фикеренчә, чынгыз < тыцыр < таңыр рәвешле фонетик үзгәрешләр кичереп, «күк алласы» дигән мәгънәне белдерә[13].

Күпсандагы антропонимик берәмлекләр Күлтәгиннең Зур һәм Кече язмаларында (732 ел), Билге каганга (Могыйлән ханга) (735), Төньюкукка (712-716), Кол Чурага (759), Енисей язмалары чыганакларындагы ядкәрләрдә сакланып калган. Бу язмаларда, антропонимик системадан тыш, борынгы төркиләрнең яшәгән урыннары,

беренче төрки дәүләтләр, ил башлыклары, аларның сәясәте, ул вакытларда яшәгән халыклар турында да мәгълүматлар бирелә. Рун һәм Енисей язмалары татар антропонимик системасының үсешен чагылдырган әһәмиятле язма чыганак булып тора, чөнки бу ташъязмаларда төгәл язылу датасы күрсәтелә. Орхон-Енисей язмаларында сакланып калган антропонимнар составында титуллар билгеләнә. Борынгы төркиләр бала тугач, аңа башта кендек исеме кушсалар, үсә төшкәч, «үсмер исеме» биргәннәр, гаскәр булгач исә егет «гаскәр исемен» ала, батырлык күрсәткәннән соң янә исеме үзгәрә. Бу күренеш Енисей язмаларында түбәндәгечә яктыртылган: oɣlan atïm čubuč ïnal ärtä ätïm kümül ögä (минем үсмер исемем – Чабуч-инал, гаскәри исемем – Огя кюмлей)[14]. Антропонимнарның семантик составы лексик компонентларның төрлелеге, шул исәптән, титулатур лексиканың кулланылуы белән билгеләнә. Орхон язмаларында, нигездә, югары катлауга караган исемнәр теркәләләр. Шуңа күрә титул атаманың исем составында кулланылуы табигый. Титул атамасы бары тик аерым бер иҗтимагый катлауны гына белдереп калмый, ә шул ук вакытта фамилия функциясен дә үти. Шулай ук фамилия функциясен кешенең этник кабиләсен белдергән атамалар да башкара. Семантик мәгънәсеннән чыгып, борынгы төрки ташъязмалардагы исемнәрнең берничә төрен билгеләргә мөмкин: Титул атамасы нигезендә ясалган борынгы төрки кеше исемнәре Орхон-Енисей, уйгур чыганакларында теркәлгәннәр (Билге Каган, Кюл Тегин, Кюл Ич Чор, Кутлуг Шад, Бойла Бага Таркан һ.б.). Борынгы төрки телдә һәм исемнәр составында түбәндәге төрки чыгышлы титул атамалары очрый: kağan, beg, buyruk, šad, katun, kan, tigin, tarkan, urungu, boyla, bilge, tamgan, inançu, oğlan, saŋgun, çigşi h.б. Кайбер титул атамаларының исем составындагы кулланылышлары түбәндәгечә билгеләнә: Buyruk / Buyuruk атамасы бөтен титул атамаларын гомумиләштерә Kutluğ Bağa Tarkan Öğe Buyruku ben (Мин – Кутлуг Бага Таракан Оге Буйрук); Beg (бәк, князь): Bilge Beg, Beg Arslan, Beg Bars, Beg Boga, beg Çur, Beg Timur, Beg Turmuş, Ürüng Beg; Çur / Çor (югары дәрәҗәгә ирешкәнче бирелә торган титул): Tegin, Beg Çur, Kül Çur, Küli Çor, Oglan Çur, Yegen Çur; Kagan (каган): Ay Kagan, Altun Kağan, Baz Kağan, Bilge Kağan, İltiriş Kağan, Kül Bilge Kağan, Kapgan Kağan, Oğuz Kagan; Boyla: Boyla Bağa Tarkan, Boya Kutltuğ Yargan; Kan/Han (хан, дәүләт башлыгы): Kan Elçi, kan Oğul, Kan Toyin, bars Kan Sangun, Böğü Kan, Kara Kan h.б. Таркан титулы төрки каганлыкларның югары гаскәри-административ иерархиясен билгели[15]. Орхон-Енисей язмаларында таркан компоненты нигезендә ясалган исемнәр: Ayluç Tarkan, Altun Tamgan Tarkan, Kegilinç Tarkan, Oğul Tarkan, İşbara Tarkan h.б. Tigin / Tegin / Tekin атамасы хан гаиләсенең түбән катлау әгъзаларында[16] чагылыш таба. Түбәндәге исемнәр билгеләнәләр: Alp Tegin, Esen Tegin, Yaruk Tigin, Kül Tigin, Kümüş Tigin, Kutlug Tigin, Oğul Tigin, Özmış Tigin h.б. Tutuk компоненты М. Кашгари сүзлегендә кеше исеме буларак билгеләнә[17]. Борынгы төрки язмаларда тутук компоненты икенче компонент буларак кулланыла. Бу сүз «баш командир» мәгънәсендә йөри: Tutuk, Adak Tutuk, Alp Tutuk, Budak Tutuk, Buzaç Tutuk, El Togan Tutuk, Yabaş Tutuk, Yağmış Tutuk, Kök Amaş Tutuk, Künç Tutuk, Öz apa Tutuk, Soyan Tu tuk, Tay Bilge Tutuk Şad (феодал): Mogilyan Şad, Kutlug Şad, Bögü Şad h.б. Čigsi/čiksi: Bağatur Çigsi, Çik Bilge Çiksi, Kül Çigsi, Kadır Çigsi, Kutlug Çiğsi, Urungu Tudun Çigsi Uruŋu (гаскәри ранг)[18]: Urungu Sangun, urungu Tudun Çigsi, Alp Urungu Tutuk, İnalUrungu, Kül apa Urungu h.б. Er (ир кеше)[19]: Er Börü, Er Boga, Er Sançmış, Er Togmuş, Er Tonga, Er Ansak Tösek, Alp Er Tonga h.б. Yabgu (ябгу) титулы каганнан соң бирелә торган титулны аңлата. Түбәндәге кеше исемнәре составында кулланыла: Dip Yabgu, Ağım Yavkuy, Kurs Yavkuy, Kay Yabğu Han, Ulamdur Yavkuy Han h.б.

Борынгы төрки телдә хатын-кыз исемнәре аз очрый. Хатын-кыз исемнәре katun компоненты нигезендә ясалалар: İlbige Katun, Oğlağu Katun, Terken Katun, Kuma Katun, Kut Tengri Katun, Turuş Katun һ.б. Димәк, алдагы мисаллардан күренгәнчә, исем һәм титул арасында чик булмый. Титул исем урынында да, аның составында да йөри. Төрки антропонимиянең үсеше процессында титуллар исем функциясен үти башлыйлар.

Орхон-Енисей язмаларында чагылыш тапкан исемнәрдә кешенең физиологик һәм рухи үзенчәлекләрен яктырткан исемнәр дә билгеләнәләр. Югары катлау вәкилләрен характерлаган эпитетлар кеше исемнәре составында кулланылган: bilgä (акыллы)[20], alp (укчы, герой, батыр)[21], külüg (танылган)[22], küçlig (көчле, куәтле)[23]. Хан, каганнарның исеменә акыл, көч, кодрәт кебек үзенчәлекләрне яктырткан сүзләр өстәлү дә очрый. Борынгы төркиләр кешегә хас үзенчәлекләрнең һәм бу кешеләрнең үзләрен дә Тәңре тарафыннан бирелүенә ышанганнар. Орхон-Енисей язмаларында болай дип языла: Tengride bolmuş, Tengri teg kut bulmuş, Tengri kötürmüş, Tengride kut bulmuş. Bilgä (акыллы)[24]: Bilgä Kağan, Bilgä Işbara Tamğan Tarkan, Bilgä Köngül Sangun, Bilgä Küli Çur, Bilgä sangun, Bilgä Tonyukuk, İnanöu Bilgä, Çik Bilgä Çiksi һ.б. Külüg (нинди дә булса характерга, үзенчәлеккә ия)[25]: Külüg Çigsi, Külüg Çur, Külüg İnan Çaça Sengün, Külüg Şangun, Külüg Tirig, Külüg Tutuk, Külüg Urungu һ.б. Kutluğ (тормыш көченә ия; бәхетле, бәхет бирүче)[26]: Kutluğ, Kutlug Bağa Tarkan, Kutluğ Bayutmış, Kuyluğ Bört, Kutluğ Oğul, Kutluğ Kağan Temir һ.б. Küç «көч»: Küç Barlığ, Küç Kül Tutuk, Küç Tegin, Küç Temir, Kılıç Küç Kara, Küç Kıyagan һ.б. Esan (сәламәт, нык)[27]: Esen, Esan Buka, Esen Kaya, Esen Tegin Esen Timur, Esen Tutuk һ.б. Ulug (зур, көчле)[28]: Ulug ordu Beg, Ulug Türük һ.б.

Билгеле булганча, борынгы төркиләрдә исем алыштыру йоласы була. Л. Н. Гумилев болай яза: «Төрки халык, европалылар кебек, туганнан бирле бер үк исемне йөртмиләр. Төрки кешенең исеме аның иҗтимагый тормышта тоткан урынын күрсәтеп торган: бала вакытта ул – кушамат йөртә, үсмер вакытта – чин, ир булгач – титул, әгәр ул хан булса, аның исеме чин баскычы нигезендә үзгәреш кичерә»[29]. Борынгы төрки һәм башка төрле тарихи чыганаклардан мәгълүм булганча, Орхон-Енисей язмалары адресат тарафыннан языла. Шуңа күрә ташъязмаларда кешенең вазифасы, тоткан урыны турында гына түгел, исеме турында да мәгълүмат бирелә. Татар антропонимиясендә ай антропокомпоненты борынгы төркиләрнең уртак хәзинәсе булып тора[30]: Ay Kağan, Ay, Ay Ölütüçü, Ay Toldu, Ay Silig, Ay Çeçek, Ay Han һ.б. Димәк, ай компонентлы исемнәрдә ел, ай календаренә бәйле традицияләр чагылыш таба. Айтуды, Айбарс, Айкилде, Айтуган, Айбулат кебек ир-ат исемнәре, татарлардан тыш, казакъларда, башкортларда, төрекмәннәрдә, үзбәкләрдә, төрекләрдә дә кулланыла. Мәсәлән, төрекләрдә Айбарс, Айтимер, Айхан, Гөкай, Аканай, Бирай, казакъларда Айтуган, Айдан, Айбас, башкортларда Айбәк, Айкилде, кыргызларда Айзат, Айнурзат кебек ир-ат исемнәре актив кулланылып, борынгы төрки катлам ир-ат исемнәрен билгелиләр. Күзәтүләребезгә караганда, бүгенге ай антропокомпонентлы Айзат, Айсаф, Айнур кебек ир-ат исемнәрендә «ай» исемнәрнең компоненты буларак кына кабул ителә, ул билгеле бер ышану-йолаларга бәйле түгел.

Орхон-Енисей язмаларында Kün, Kün Bermiş Sengün, Kün Doğdu кебек исемнәрнең кулланылышы күзәтелә. Әлеге антропокомпонент нигезендә Көнбай, Көнбак, Көнтимер, Көнбирде, Көнтумыш, Көнсылу кебек исемнәр ясалганнар. «Көн – яктылык, матурлык, ирек символына нигезләнеп ясалган ир-ат исемнәре төрки халыкларда, шул исәптән болгар-татарларда кулланылышта актив йөргәннәр»[31]. Бу

компонент нигезендә ясалган ир-ат исемнәре, матурлык, яктылык символы булып килү белән бергә, баланың туу вакытын да билгели булса кирәк.

Татар антропонимиясендә борынгы төрки катламны тәшкил итүче бер төркем ир-ат исемнәре хайван, кош-корт культы белән бәйле атамалар нигезендә ясалганнар һәм ир-ат исемнәренең спецификасын тәшкил итәләр. Ир-ат исемнәрендә ерткыч хайван атамалары кулланылса, хатын-кыз исемнәрендә матур хайван атамалары кулланыла: Bars (тигр)[32]: Bars Beğ, Bars Kan Sangun, Bars Urungu, Kutadmış Bars, Küç Barslığ, Bars Boğa, Tüz Bay Bars, Kara Bars, Oğul Bars; Arslan (арслан)[33]: Arslan Tegin, Arslan Balban, Arslan Çik Toğrıl, Çiğil Arslan; Toğrul (ерткыч кош)[34]: Adam Toğrul, Alp Toğrul, Basa Toğrıl, Ozmış Toğrul, Kutan Toğrıl. Хайван, кош-корт культы татар хатын-кыз исемнәрендә аз чагылуы белән характерлана. Гомумтөрки бүре культы бик борынгы заманнардан килә. Шулай ук күчмә, мал асраучылык белән шөгыльләнгән халыклар тормышында бүре зур роль уйнаган дип әйтә алабыз. Борынгы Кытай чыганакларына караганда, төрки атлы гаскәрләренең иң яхшыларын «бүреләр» дип йөрткәннәр, борынгы төрки язмаларда «аларга күк көч биргәнгә күрә, минем атам каганның гаскәре бүре кебек» диелә. «Бүре сүзе борынгы төркиләрдә кеше исемнәре ясалышында да киң кулланыла. Моны аеручa затлы нәселдән чыккан кеше исемнәрендә күреп була»[35]. Болгар-татарларда бүре сүзен изге, илаһи сүз санап кешегә исем итеп бирү йоласы барлыкка килә. Бүре сүзе борынгы төрки телдә бөрө, борүг формасында килеп, аның синонимы булган кашкар, кашкур, корт сүзләрен, монгол телендәге ашан һәм чаны сүзләрен ир балаларга исем итеп кушканнар[36]. Р. Әхмәтьянов бүре сүзенең борынгы ирани телләрдән алынуын һәм мари телендә пириге, пирагу, мукшыда виргас сүзләренең кулланылуын искәртеп китә[37]. Татарларда бүре антропокомпоненты Бүребай, Бүрекәй, Бүриш, Бүрехан, Башбүре һәм башка ир-ат исемнәрендә кулланылган. Болгар җирендә табылган һәм борынгы генеологик риваятьне чагылдырган сыннарда гомумтөрки тотем – бүре болгар тотемы – барска алыштырыла[38].

Татар антропонимиясендә барс культы ир-ат исемнәрендә чагылыш тапкан. Г. Ф. Саттаров болгар-татарларда изге барс тотемына нисбәтле рәвештә ир бала барс кебек көчле, кодрәтле булып үссен дигән теләктән чыгып та һәм борынгы төрки календарь буенча барс елында туган ир балага барс исемен кушу йоласы булуын билгели[39]. Барс компоненты нигезендә Барсбай, Барсби, Барсбуга, Барсбәк, Барсхан кебек ир-ат исемнәре ясалган. Борынгыдан килгән ышануларга караганда, төрки халыкларда җанварлар арасында арыслан көч, гайрәт һәм затлылык символы булып санала. Татарларда, шул исәптән, башка төрки халыкларда да Арслан-Арыслан-Аслан исеме кушыла торган булган. Галимнәр бүгенге көндә ир балалар арасында еш кушылучы исемнәрнең берсе Руслан исемен Арслан исеменең славянлашкан формасы дип карыйлар[40].

Төрки халыкларда кайбер металл атамаларыннан ясалган ир-ат исемнәре борынгы төрки катламны тәшкил итәләр. Төрки халыкларда корал кою өчен кирәкле металл – тимер җансыз предметларны олылау, изгеләштерү стихиясен чагылдырган. Тимер төрки халыкларның килеп чыгышы белән бәйле күп кенә легенда-риваятьләрдә дә телгә алына. Һуннар римлыларда «Марс кылычы» булып саналган тимергә табынганнар, кесәләрендә бөти урынында йөргән тимер пычакны үзләре белән йөрткәннәр.

Төрки империясенең чикләрендә Византия илчеләренә дини тантаналы кичәләр барышында тимер бүләк иткәннәр. Милли исемнәрдән саналган Тимер, Тимерташ, Һичшиксез, дини эчтәлеккә ия ир-ат исемнәре булырга тиеш», дип билгели Л. Гумилев[41]. Борынгы төрки сүзлектә temür tuya, baj temür, eltemür, esân

temür кебек ир-ат исемнәре теркәлгән[42]. Бу антропокомпонент бары тик ир-ат исемнәренең үзенчәлекле компоненты булып килә. Мисал итеп тимер антропокомпонентлы Тимербай, Тимерәй, Тимәш, Тимеркәй кебек ир-ат исемнәрен күрсәтергә мөмкин. Тимер исеме төрки халыклардан русларга үтеп кереп фонетик үзгәреш кичергән хәлдә, XX гасыр урталарында татар антропонимикасына Тимур формасында кире әйләнеп кайта. Шулай ук, татарларда Тимерхан «тимер+хан», Тимерлан «тимер+олан» (бор. тат. [о > у] оглан > углан), «асыл-зат егет, гвардия солдаты»,Минтимер «миң+тимер», Тимербулат «тимер+булат» кебек исемнәр кулланылышка керә башлады.

Исем – ул тарих, аерым бер кешенең тарихы, гаилә тарихы, милләт тарихы, ил тарихы. Борынгы төрки катламга караган исемнәр бүген дә антропонимик системабызда актив кулланылышта, исем системасының үзәген тәшкил итәләр һәм яңа исемнәр ясауда зур роль уйныйлар. Татар халкының гасырлар дәвамында кардәш һәм кардәш булмаган халыклар белән сәяси-иҗтимагый-мәдәни бәйләнешләре антропонимик системаның үсеш үзгәрешенә, тулылануына, аерым бер катлам исемнәрнең барлыкка килүенә китерсә дә, борынгы төрки катламга караган исемнәр киңкырлы функциягә ия дип әйтергә нигез бар. Шуңа күрә билгеле бер тарихи-лингвистик һәм географик алшартларда, төрле кавем халыкларның үзара коммуникатив арадашлыгы процессында формалашкан татар исемиятендә этнолингвистик катламнарның төрлелеге исемнәренең тарихи-лингвистик үсешен «катып калган» система эчендә генә түгел, бәлки кеше эшчәнлеге нәтиҗәсе итеп карарга мөмкинлек бирә. Әлеге үзенчәлек бары тик татар антропонимик системасы өчен генә түгел, мисаллардан күренгәнчә, башка төрки антропнимик системаларда да үзәк урынны алып тора.

**ИСКӘРМӘЛӘР:**


1. *Дәүләтшин Г.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – Б. 429.

2. *Шайхулов А.Г.* Татарские и башкирские личные имена тюркского происхождения. – Уфа, 1983. – 72 с.

3. *Erol A.* Adlarımız. – Istanbul: Turan Kültür Vakfi, 1999. – S. 345.

4. *Бегматов Э.А.* Ўзбек исмлари маъноси (изохли луғат). – Тошкент: Ўзбекистон миллий энциклопедияси (луғат), 2007. – S. 45

5. *Жанузак Т.* Есімдер сыры. – Алматы, 2004. – Б. 40.

6. *Кляшторный С.Г.* Мифологические сюжеты в древнетюркских памятниках // Тюркологический сборник. – М.: Наука: Изд-во вост. лит, 1981. – С. 138.

7. *Исхаков Д.М. Измайлов И.Л.* Этнополитическая история татар (III – середина XVI вв.). – Казань: РИЦ «Школа», 2007. – 356 с.

8. *Гумилев Л.* Древние тюрки. – М.: Наука, 1967. – С. 51; *Дәүләтшин Г.* Күрс. хез. – Б. 429; *Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Татар дастаннарында миф һәм эпик контаминацияләр гармониясе // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2018. – Б. 159-172.

9. *Жанузак Т.* Есімдер сыры. – Алматы, 2004. – Б. 40.

10. *Бегматов Э.А.* Ўзбек исмлари маъноси (изохли луғат). – Тошкент: Ўзбекистон миллий энциклопедияси (луғат), 2007. – S. 68.

11. *Жапаров Ш.* Адам аттары – эл байлыгы. – Бишкек, 2009. – Б. 43.

12. *Erol A.* Adlarımız … – S. 234.

13. *Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 том (М-Я). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 67 б.

14. *Кормушин И. В.* Тюркские енисейские эпитафии: грамматика, текстология. – М.: Наука, 2008. – С. 42.
15. *Кляшторный С. Г.* Указ. соч. – С. 115.
16. Древнетюркский словарь. – Л.: Наука, 1969. – С. 547.
17. *Kaşgarlı M.* Divanü lügat-it-Türk. C. V. – Ankara: Türk Dil Kurumu, 2006. – S. 661.
18. *Кормушин И. В.* Указ. соч. – 34 с.
19. Древнетюркский словарь… – С. 175.
20. Там же. – С. 99.
21. Там же. – С. 36.
22. Там же. – С. 26.
23. Там же. – С. 3.
24. Там же. – С. 86.
25. Там же. – С. 56.
26. Там же. – С. 76.
27. Там же. – С. 96.
28. Там же. – С. 76.
29. *Гумилев Л.* Указ. соч. – С. 82.
30. Древнетюркский словарь… – С. 27.
31. *Саттаров Г. Ф.* Татар антропонимикасы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1990. – Б. 56.
32. Древнетюркский словарь… – С. 84.
33. Там же. – С. 76.
34. Там же. – С. 56.
35. *Дәүләтшин Г.* Күрс. хез. – Б. 65.
36. *Саттаров Г. Ф.* Күрс. хез. – Б. 26.
37. *Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге. 1 том (А-Л). – Казан: Вакыт, Мәгариф, 2015. – Б. 222.
38. *Дәүләтшин Г.* Күрс. хез. – Б. 98.
39. *Саттаров Г. Ф.* Күрс. хез. – Б.76.
40. *Суперанская А. В.* Словарь русских личных имен. – М.: Эксмо, 2005. – С. 222.
41. *Гумилев Л.* Указ. соч. – С 123.
42. Древнетюркский словарь… – С. 533.

**Әдәбият исемлеге**

*Ашмарин Н. Г.* Материалы по исследованию чувашского языка. – Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1898. – 392 с.

*Булатова М. Р.* Термины родства в курмантауском говоре татарского языка // Традиционная культура народов Поволжья: материалы IV Всероссийской научно-практической конференции с международным участием. – Казань: Ихлас, 2018. – С. 64-69.

*Гарипов Т. М.* О древних кипчакских именах в антропонимии башкир // Ономастика Поволжья. – Уфа, 1973. – Вып. 3. – С. 52-54.

*Гумилев Л.* Древние тюрки. – М.: Наука, 1967. – 501 с.

*Дәүләтшин Г.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 512 б.

*Дмитриев Н. К.* Строй тюркских языков. – М.: Изд-во вост. Литературы, 1968. – 342 с.

*Жанузак Т.* Есімдер сыры. – Алматы, 2004. – 208 б.

*Жапаров Ш.* Адам аттары – эл байлыгы. – Бишкек, 2009. – 343 б.

*Исхаков Д. М. Измайлов И. Л.* Этнополитическая история татар (III – середина XVI вв.). – Казань: РИЦ «Школа», 2007. – 356 с.

*Кляшторный С. Г.* Мифологические сюжеты в древнетюркских памятниках // Тюркологический сборник. – М.: Наука: Изд-во вост. лит, 1981. – С. 115-138.

*Кормушин И. В.* Тюркские енисейские эпитафии: грамматика, текстология. – М.: Наука, 2008. – 342 с.

*Курышжанов А. К.* Исследование по лексике старокыпчакского письменного памятника XIII в. – «Тюрко-арабский словарь». – Алма-Ата: Наука, 1970. – 232 с.

*Саттаров Г. Ф.* Татар антропонимикасы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1990. – 276 б.

*Шайхулов А. Г.* Татарские и башкирские личные имена тюркского происхождения. – Уфа, 1983. – 72 с.

*Хакимзянов Ф. С.* Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык. – М.: Наука, 1987. – 191 с.

*Хаков В.* Тел – тарих көзгесе. – Казан: Татарстан китап нәшр., 2003. – 295 б.

*Хазиева Г. С.* Татарские личные имена в этнокультурном пространтстве. – Казань: Магариф-вакыт, 2017. – 444 с.

*Хусаинова А. Я.* Термины свойственного родства в татарских говорах Оренбуржья // Вестник ВЭГУ. – 2013. – № 4. – С. 208-211.

*Юсупов Г. В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.: Наука, 1960. – 165 с.

*Erol A.* Adlarımız – Istanbul: Turan Kültür Vakfi, 1999. – 610 s.

*Kaşgarlı M.* Divanü lügat-it-Türk. C. V. – Ankara: Türk Dil Kurumu, 2006. – 873 s.

*Tekin T.* Orhon Yazıtları. – Ankara: Türk Dil Kurumu, 2008. – 200 s.

**References**

Ashmarin N. G. *Materialy po issledovaniyu chuvashskogo yazyka* [Materials on the study of the Chuvash language]. Kazan, Tipo-litogr. Imp. un-ta publ., 1898, 392 p.

Bulatova M. R. *Terminy rodstva v kurmantauskom govore tatarskogo yazyka* [Kinship terms in Kurmantau subdialect of the Tatar language]. IN: *Traditsionnaya kultura narodov Povolzhya: materialy IV Vserossiyskoy nauchno-prakticheskoy konferentsii s mezhdunarodnym uchastiem* [Traditional culture of the Volga Region peoples: proceedings of the IV Russian Scientific And Practical Conference with international participation]. Kazan, Ikhlas publ., 2018, pp. 64-69.

Garipov T. M. *O drevnih kipchakskih imenah v antroponimii bashkir* [On Old Kipchak names in Bashkir anthroponymy]. IN: *Onomastika Povolzhya*. Ufa, 1973, vol. 3, p. 52-54.

Gumilev L. *Drevnie tyurki* [Old Turks]. Moskow, Nauka publ., 1967, 501 p.

Davletshin G. *Torki-tatar ruhi medeniyate tarihy* [History of the Turko-Tatar culture]. Kazan, Tatar. kit. nashr. publ., 1999, 512 p.

Dmitriyev N. K. *Stroy tyurkskih yazykov* [Structure of Turkic Languages]. Moskow, Izd-vo vost. Literatury publ., 1968, 342 p.

Erol A. *Adlarımız* [Our names]. Istanbul, Turan Kültür Vakfi publ., 1999, 610 p.

Zhanuzak T. *Esimder syry* [The mystery of the name]. Almaty, 2004, 208 p.

Zhaparov Sh. *Adam attary – ehl baylygy* [The names of the state's wealth]. Bishkek, 2009, 343 p.

Ishakov D. M., Izmaylov I. L. *Etnopoliticheskaya istoriya tatar (III – seredina XVI vv.)* [Ethnopolitical history of Tatars]. Kazan, Shkola publ., 2007, 356 p.

Klyashtorny S. G. *Mifologicheskie syuzhety v drevnetyurkskih pamyatnikah* [Mythological themes in the Old Turkic monuments]. IN: *Tyurkologicheskiy sbornik.* Moskow, Nauka: Izd-vo vost. lit publ., 1981, pp.115-138.

Kormushin I. V. *Tyurkskie yeniseyskie epitafii: grammatika, tekstologiya* [Turkic Yenisei epitaphs: grammar, textology]. Moskow, Nauka publ., 2008, 342 p.

Kuryshzhanov A. K. *Issledovanie po leksike starokypchakskogo pismennogo pamyatnika XIII v. – "Tyurko-arabskiy slovar"* [Research on the vocabulary of the Old Kypchak written monument of the 13th century. – Turkic-Arabic dictionary]. Alma-Ata, Nauka publ., 1970, 232 p.

Sattarov G. F. *Tatar antroponimikasy* [Tatar anthroponymy]. Kazan, Kazan un-ty nashr. publ., 1990, 276 p.

Kaşgarlı M. *Divanü lügat-it-Türk*. Ankara, Türk Dil Kurumu publ., 2006, 873 p.

Khusainova A. Y. *Terminy svoystvennogo rodstva v tatarskih govorah Orenburzhya* [Terms of kinship peculiar to the Tatar subdialects of Orenburg region]. IN: *Vestnik VEHGU*, 2013, no. 4, pp. 208-211.

Khakimzyanov F. S. *Epigraficheskie pamyatniki Volzhskoy Bulgarii i ih yazyk* [Epigraphic monuments of the Volga Bulgaria and their language]. Moskow, Nauka publ., 1987, 191 p.

Khaziyeva G. S. *Tatarskie lichnye imena v etnokulturnom prostrantstve* [Tatar personal names in the ethnocultural space]. Kazan, Magarif-vakyt publ., 2017, 444 s.

Khakov V. *Tel – tarih kuzgese* [Language is the mirror of the nation]. Kazan, Tatarstan kitap neshr publ., 2003, 295 p.

Shaykhullov A. G. *Tatarskie i bashkirskie lichnye imena tyurkskogo proishozhdeniya* [Tatar and Bashkir personal names of Turkic origin]. Ufa, 1983, 72 p.

Yusupov G. V. *Vvedenie v bulgaro-tatarskuyu ehpigrafiku* [Introduction to the Bulgar-Tatar epigraphy]. Moskow, Nauka publ., 1960, 165 p.

Tekin T. *Orhon Yazıtları* [Orkhon inscriptions]. Ankara, Türk Dil Kurumu publ., 2008, 200 p.

## Сведения об авторе

***Хазиева Гузалия Сайфулловна,*** доктор филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, e-mail: guzhaz@mail.ru.

## About the author

***Guzaliya S. Khaziyeva,*** Doctor of Philological Sciences, Senior Researcher at Department of Lexicology and Dialectology, G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, e-mail: guzhaz@mail.ru.

## В редакцию статья поступила 19.07.2019, опубликована:

*Хажиева Г.* С. Татар ономастиконында борынгы төрки исемнәр // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2019. – № 3. – С. 16-25.

## Submitted on 19.07.2019, published:

Khaziyeva G. S. *Tatar onomastikonynda boryngy torki isemner* [Old Turkic personal names in the Tatar onomasticon]. IN: *Gasyrlar avazy – Eho vekov*, 2019, no. 3, pp. 16-25.